МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

25.10.2021 Казан ш. № 3236-р

**Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналарын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 19.12.2015 № 3233-р карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «Земля» РКҮ АҖ башкарган документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе хатын исәпкә алып (04.10.2021 № 1256/05), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Газпром трансгаз Казань» милке булган, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында” 19.12.2015 № 3233-р карары (алга таба - № 3233-р Карар) белән урнаштырылган 58,24 м. озынлыктагы, 18857 инвентарь номерлы газүткәргеч өлешенең 16:50:010618:397, 16:50:000000:30582 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге саклау зонасын бетерергә.

2. “Казан шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендә булган 579 м озынлыктагы, гомуми территориясенең мәйданы 47 кв.м ± 2 кв.м булган, 18857 инвентарь номерлы газүткәргеч өлешләренең 16:50:010618:397, 16:50:000000:30582 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге саклау зоналарын, газүткәргечкә реконструкция ясалу сәбәпле, «Земля» республика кадастр үзәге” АҖ әзерләгән территорияне кулланунның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, җир асты һәм җир өсте объектлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге буенча расларга.

3. Әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән һәм өлешчә яки тулысынча күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зонасына туры килгән җир кишәрлекләренә 18857 инвентарь номерлы газүткәргеч өлешләренең эксплуатация срогында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. «Земля» республика кадастр үзәге” АҖ әзерләгән территорияне кулланунның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, газүткәргеч чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә № 3233-р карарга (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 24.01.2017 № 107-р, 22.06.2017 № 1378-р, 13.07.2017 № 1608-р, 29.08.2017 № 1977-р, 28.09.2017 № 2191-р, 22.09.2017 № 2155-р, 22.08.2018 № 2563-р, 31.08.2018 № 2653-р, 05.12.2018 № 4140-р, 25.06.2019 № 1970-р, 07.08.2019 № 2419-р, 05.11.2019 № 3520-р, 21.01.2020 № 117-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең саклау зоналарын урнаштыру турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Казаньгоргаз» ЭПУның Казан ш. территориясендә (Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет районнары) урнашкан 1 453,10767 км озынлыктагы, әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү челтәрләре (газүткәргечләр) саклау зоналарын «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «Земля» республика кадастр үзәге» АҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектлары картасында (планында) булган белешмәләр нигезендә расларга.»;

1 нче кушымтада:

18857 инвентарь номерлы газүткәргечкә туры килгән юлны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «239 | 18857 | 4928 | Татарстан Республикасы, Казан ш., Вахитов районы, Мөштәри ур. | 11,69 | Түбән басымлы газүткәргеч, җир асты, полиэтилен; d = 57. | 16-50.3-23.2001-1046.1 24.10.2001 ел.»; |

2 нче кушымтада:

16:50:010618:397, 16:50:000000:30582 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә туры килгән юлларны төшереп калдырырга;

Әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы юллар белән тулыландырырга.

5. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
25.10.2021 № 3235-р
карарына кушымта

<table>
<tr><td>"18857</td><td>ТР, Казан ш., Авиатөзелеш районы, Борисоглебское торак массивы, Кече Заречная</td><td>Милек</td><td>Милек</td><td>16:50:010618:397</td><td>Торак пунктлар җирләре</td><td rowspan="2">47</td><td>Бикаева Гульнур Герфановна</td><td>Аз катлы күп фатирлы торак йорт төзелеше; Оторак төзелешенә хезмәт күрсәтү; эшкуарлык</td></tr>
<tr><td>18857</td><td>ТР, Казан ш., Вахитов районы</td><td>-</td><td>-</td><td>16 50 000000 30582</td><td>Торак пунктлар җирләре</td><td>Казан шәһәренең Башкарма комитеты</td><td>Коммуналь хезмәтләр күрсәтү</td></tr>
</table>